| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 15 март № 142

г. Казань

2017 – 2018 елларга Татарстан Республикасы акционерлык җәмгыятьләренең директорлар советларындагы һәм ревизия комиссияләрендәге Татарстан Республикасы вәкилләре турында

«Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы икътисады өчен аеруча мөһим әһәмияткә ия Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре, акцияләре Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган акционер җәмгыятьләр исемлеген раслау турында» 2004 елның 8 октябрендәге 614-ПУ номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 20 гыйнварындагы 28 – 30, 32 – 34, 50 – 52, 56, 58 номерлы боерыклары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы вәкилләрен махсус хокук («алтын акция») нигезендә түбәндәгеләргә билгеләргә:

әлеге карарга теркәлгән 1 нче кушымта нигезендә – акционерлык җәмгыятьләренең директорлар советларына;

әлеге карарга теркәлгән 2 нче кушымта нигезендә – акционерлык җәмгыятьләренең ревизия комиссияләренә.

2. Әлеге карарга теркәлгән 1 нче һәм 2 нче кушымталарда күрсәтелгән акционерлык җәмгыятьләренең директорлар советларындагы һәм ревизия комиссияләрендәге Татарстан Республикасы вәкилләре урыннары директорлар советлары һәм ревизия комиссияләре әгъзаларын сайлаганда исәпкә алынмый, дип билгеләргә.

3. 100 процент акцияләре Татарстан Республикасы милкендә булган «Химград» ачык акционерлык җәмгыяте директорлар советына Татарстан Республикасы вәкилләрен әлеге карарга теркәлгән 3 нче кушымта нигезендә билгеләргә.

4. «Радиоприбор» акционерлык җәмгыяте директорлар советына сайлау өчен Татарстан Республикасы вәкилен әлеге карарга теркәлгән 4 нче кушымта нигезендә тәкъдим итәргә.

5. 2017 елда акционерларның еллык гомуми җыелышларын үткәргәннән соң һәм әлеге карар белән билгеләнгән Татарстан Республикасы вәкилләре арасыннан акционерлык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшерү органнарының яңа составын формалаштырганнан соң, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2017 елларга Татарстан Республикасы акционерлык җәмгыятьләренең директорлар советларындагы һәм ревизия комиссияләрендәге Татарстан Республикасы вәкилләре турында» 2016 ел, 17 февраль, 97 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\142.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 15 март, 142 нче карарына 1 нче кушымта

Акционерлык җәмгыятьләренең директорлар советларына махсус хокук («алтын акция») нигезендә билгеләү өчен Татарстан Республикасы вәкилләре исемлеге

1. «Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте:
Хамаев Азат Кыям улы – Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры.

2. «Казан органик синтез» гавами акционерлык җәмгыяте:
Сабиров Ринат Касыйм улы – Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе.

3. «Түбән Кама нефть химиясе» гавами акционерлык җәмгыяте:
Сабиров Ринат Касыйм улы – Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе.

4. «Татхимфармпрепараты» акционерлык җәмгыяте:
Вафин Адел Юныс улы – Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры.

5. «Татспиртпром» акционерлык җәмгыяте:
Халиков Илдар Шәфкать улы – Татарстан Республикасы Премьер-министры.

6. «Камгэсэнергострой» гавами акционерлык җәмгыяте:
Фәйзуллин Ирек Әнвәр улы – Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры.

7. «Казан вертолет заводы» гавами акционерлык җәмгыяте:
Зарипов Равил Хаммат улы – Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе.

8. «Түбән Кама техник углерод заводы» акционерлык җәмгыяте:

Савельчев Алексей Петрович – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 15 март, 142 нче карарына 2 нче кушымта

Акционерлык җәмгыятьләренең ревизия комиссияләренә махсус хокук («алтын акция») нигезендә билгеләү өчен Татарстан Республикасы вәкилләре исемлеге

1. «Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте:
Борзунова Ксения Геннадьевна – Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының бүлек башлыгы.

2. «Казан органик синтез» гавами акционерлык җәмгыяте:
Габделхаков Фәнис Габделфәт улы – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының бүлек башлыгы.

3. «Түбән Кама нефть химиясе» гавами акционерлык җәмгыяте:
Габделхаков Фәнис Габделфәт улы – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының бүлек башлыгы.

4. «Татхимфармпрепараты» акционерлык җәмгыяте:
Миңнуллин Марсель Гомәр улы – Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының бүлек башлыгы.

5. «Татспиртпром» акционерлык җәмгыяте:
Насыртдинов Олег Рәшит улы – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының идарә башлыгы урынбасары.

6. В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте:
Йосыпова Сәрия Кәшибелхак кызы – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының бүлек башлыгы урынбасары.

7. «Камгэсэнергострой» гавами акционерлык җәмгыяте:
Газизуллина Тәслия Сәлимҗан кызы – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Чаллы шәһәре территориаль бүлегенә караган районара тикшерү-ревизия бүлеге башлыгы.

_______________

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 15 март, 142 нче карарына 3 нче кушымта

100 процент акцияләре Татарстан Республикасы милкендә булган
«Химград» акционерлык җәмгыяте директорлар советына билгеләү өчен
Татарстан Республикасы вәкилләре
исемлеге

Кәримов Альберт Әнвәр улы – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры;

Воронина Юлия Владимировна – Татарстан Республикасы Президентының Эксперт департаменты баш киңәшчесе.

______________________________

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 15 март, 142 нче карарына 4 нче кушымта

«Радиоприбор» акционерлык җәмгыяте
директорлар советына тәкъдим итү өчен Татарстан Республикасы вәкилләре
исемлеге

Нефедов Андрей Александрович – Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы урынбасары.

---